**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**29 июнь, 2023 ел** **№ 307**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аеруча саклана торган табигый территорияләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, 2023 елның 23-24нче июнендәге Биектау авыл җирлеге торак пунктларында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 31 гыйнварындагы 141 номерлы карары (19.09.2022 № 205 белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Шәһәр төзелеше регламентлары» 19 статьясындагы «Индивидуаль торак төзелеше зонасы (Ж1)» һәм « Аз катлы күпфатирлы торак төзелеше зонасы (Ж2)» бүлекләрен түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Әлеге пунктта каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәре гражданнарга әлеге кагыйдәләр расланганнан соң бирелә торган җир кишәрлекләренә (яңа бүлеп бирелә торган җир кишәрлекләренә) кагыла дип билгеләргә.

Әлеге пунктта каралган җир кишәрлекләренең иң чик (максималь һәм минималь) күләмнәре гражданнарга аренда хокукларында бирелгән һәм алар тарафыннан әлеге кагыйдәләр расланганчы гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә милеккә алына торган җир кишәрлекләренә кагылмый дип билгеләргә.

Гражданнарның фактта файдалануындагы яисә әлеге кагыйдәләр расланганчыга кадәр бирелгән төзелә торган җир кишәрлегенең күләме иң чик минималь күләмнәрдән кимрәк йә әлеге пунктта каралган иң чик максималь

күләмнәрдән артып киткән очракларда, әлеге җир кишәрлеге өчен аның күләмнәре тиешенчә минималь яисә максималь чик күләмнәрдән гыйбарәт була.

Иң чик күләмнәргә карата искәрмә булып, нормадан артып киткән кишәрлекнең бер өлеше мөстәкыйль җир кишәрлеге буларак формалаша алмаганда һәм кызыксынган катнаш җир кулланучыларының ризалыгы шартта, максималь күләмнәрдән артып киткән җир кишәрлекләре тора.

Шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән җир кишәрлекләренең чик (минималь,) күләмнәре кулланылмый:

- дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән җир кишәрлеге төзү;

-гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләмнәренә туры килә торган җир кишәрлеген төзү мөмкинлеге булмау.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов